**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования и науки Республики Татарстан**

**Исполнительный комитет Зеленодольского муниципального района РТ**

**МБОУ "Бишнинская ООШ ЗМР РТ"**

| | | |
|---|---|---|
| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| Руководитель ШМО начальных классов | Заместитель директора по УВР | Директор школы |
| ________________ /Идиатова Т.К./ | ________________ /Гарифуллина Г.Ю/. | ________________ /З.М.Сабирова/ |
| от «4» сентября 2024 г. | | Приказ№ 110-ОД от «26» августа 2024 г. |

# РАБОЧАЯ ПРОГРАММА

**учебного предмета «Родной язык»**

для обучающихся 4 классов

**с.Бишня 2024 год**

## Аңлатма язуы

## “Туган теле” укыту предметының эш программасы түбәндәге норматив документларга нигезләнеп төзелде

РФ “Мәгариф турында”гы Законы (№273 –ФЗ 29.12.2012 ел);

1. РТ “Мәгариф турында”гы Законы (№68-ЗРТ 22.07. 2013 ел);
2. 06.10.2009 нчы елда РФ Мәгариф һәм Фән министрлыгы тарафыннан расланган “Гомуми башлангыч белем бирү федераль дәүләт стандартын гамәлгә кертү” турындагы боерыгына (№373 боерыгы);
3. “Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Бишнә төпгомуми белем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белем учреждениесенең 2019-2020 нче уку елына укыту планы;
4. “Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Бишнә төп гомуми белеем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белеем учреждениесенең Уставы
5. “Татарстан Республикасы Зеленодол муниципаль районы Бишнә төп гомуми белеем мәктәбе" муниципаль бюджет гомуми белеем учреждениесенең педсовет утырышының 2019 нчы елның 29 августы 1нче № лы боерыгы белән расланган укытучының эш программалары турында нигезләмә;
7 Дәүләт стандартының Федераль компонентына нигезләнгән башлангыч мәктәпләрнең татар теле фәненнән үрнәк программасы.

**Укыту предметына гомуми характеристика**

Перспектив башлангыч мәктәпнең 1-4 сыйныфында укучылар аваз белән хәрефне аерырга өйрәнәләр, сүз басымы, исем, сыйфат, фигыль турында башлангыч мәгълүмат алалар. Балалар сөйләм берәмлеге буларак җөмлә турындатөшенчә ала, терминнарны әйтмичә генә , җөмләдәге баш кисәкләрне, өстәмә предметны белдергән сүзләрне һәм ярдәмче сүзләрне табу һәм урынын билгеләү кебек эш төрләренә өйрәнә. Дәресләрдә җөмләләрне төрле тавыш белән әйтү, сүзләрдән җөмләләр, җөмләләрдән кечкенә хикәяләр төзи белү күнекмәләре булдырыла.

Дәресләрдә укучыларның сөйләменә хас булган ялгышлар төзәтелә, аларны булдырмас өчен дәресләрдә балаларга атап чыгарылган газета-журналлардан, китаплардан да файдаланырга мөмкин.

Укытучы балаларның сүзлекчә булдыруларын һәм өйрәнелә торган сүзләрнең махсус дәфтәргә язып баруларын таләп итә.Еш кына шул сүзләр белән сүзтезмә һәм җөмләләр төзетү. Аларны диалог һәм монологлар төзүдә файдалану укучыларның сүз байлыгын арттырачак, бәйләнешле сөйләм үстерүгә ярдәм итәчәк. Әлеге сүзлекне даими рәвештә тикшереп тору укучыларның сүз белән эшли белү дәрәҗәсен өйрәнү өчен дә кирәк булачак.

Сөйләм телен үстерү, сүз байлыгын арттыру төрле язма эшләр үтәгән вакытта да алып барыла. Сүзлек һәм аңлатмалы диктантлар, укытучы биргән җөмләләрне (яки зур булмаган текстны) күчереп язу, матур язу күнегүләрен үтәү кебек эшләр дә андый күнекмәләр булдырырга ярдәм итә. Билгеле, мондый язма эшләр балаларның яшь үзенчәлегенә туры китереп, телне белү дәрәҗәсен истә тотып сайланган текст белән була.

Сөйләм телен үстерү уку дәресләре белән бергә дәвам иттерелә. Татар теле дәресләрендә халык авыз иҗаты үрнәкләреннән табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр, санамышлар ятлау, аларны дәфтәргә дөрес һәм матур итеп язып кую дабалаларны татарча аңлаешлы, әдәби нормаларга туры килердәй итеп сөйләргә өйрәтүдә зур әһәмияткә ия булып тора. Укучыларның мәгълүматлылыгын арттыру өчен, дәресләрдә күренекле татар язучыларының әсәрләреннән өзекләр куллану, татар композиторлары, рәссамнары һәм сәнгатьәһелләре турында әңгәмәләр оештыру нәтиҗәле булачак.

## Башлангыч сыйныфта предметны өйрәнүнең максатлары һәм бурычлары

Татар теленнән гомуми башлангыч белем бирүнең **максатлары**:

- татар телендә аралашу күнекмәләре булдыру;
- тел чараларын аралашу эчтәлегеннән чыгып сайлый белергә өйрәтү;
- тел белеменең фонетика, лексика, грамматика бүлекләре буенча башлангыч белем бирү, өйрәнелә торган тел берәмлекләрен тикшерә һәм куллана белү күнекмәләрен булдыру;
- сөйләм эшчәнлегенең барлык төрләре буенча күнекмәләр формалаштыру;
- укучыларда татар теленә хөрмәт һәм ихтирам тәрбияләү, телнең чисталыгын, дөреслеген саклау. Телне, халыкның рухи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту.

Тәкъдим ителә торган программада татар теленә өйрәтүнең **бурычлары** түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Укучыларда ана телен өйрәнүгә кызыксыну, омтылыш, эзләнергә теләк уяту, үз милләтеңә, телеңә мәхәббәт тәрбияләү кебек уңай сыйфатлар булдыру.

Балаларга татар теленең төрле бүлекләре буенча белем бирү:

а) фонетика,лексика грамматикага караган башлангыч мәгълүмат бирү;

ә) телебезнең орфоэпиясе, лексикасы, грамматикасы, пунктуациясе буенча күнекмәләр булдыра башлау. Хәрефләрдән иҗекләр һәм сүзләр, сүзләрдән сүзтезмәләр һәм җөмләләр төзергә өйрәтү.
3. Укучыларны дөрес,матур итеп укырга, укыганның эчтәлеген сөйләргә, аерым темалар буенча әңгәмәләр кора белергә, аралашканда тел чараларыннан урынлы файдаланырга өйрәтү.
4. Телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләре булдыру.
5. Укучыларда татар мәдәниятенә караган мәгълүматлылыкны үстерү.

## Уку фәненең уку планында тоткан урыны

Татар теле 4 сыйныфта атнага 3 сәг. исәбеннән- 105 сәг. (35 уку атнасы) укытыла.

## Укытуның планлаштырылган нәтиҗәләре

**Шәхси нәтиҗәләр:**

-туган ил һәм халкың һәм тарих өчен горурлык хисе кичерү; үзеңнең милли һәм этник яктан кая керүеңне аңлап, рухи кыйммәтләр булдыру;
-дөньга, аның табигать, халык, мәдәният, дин бергәлегенә карата тулы социаль юнәлештәге караш формалаштыру;
-башкаларның хис-тойгыларын аңлау, борчылу, кайгы-шатлыгын уртаклашу.
-Үз хисләреңне, тойгыларыңны атый һәм аңлата белү;
-Башка кешеләрнең хис-тойгыларын таный белү, башкаларга теләктәшлек күрсәтә белү; ярдәм итә белү;
-Сөйләм матурлыгын күрә, аның белән соклана белү; үзеңнең сөйләмеңне сәнгатьле итәргә тырышу;
-Укырга теләк булу;
-Телне өйрәнүгә теләк булу;
-Әйткән һәм язган сүзләрең өчен җаваплылык хисләре булу;
Бу нәтиҗәләргә ирешүнең ысуллары булып, дәреслектәге текстлар, алар буенча сораулар һәм биремнәр, проблемалы диалоглар тора.

**Метапредмет нәтиҗәләр:**

-укытучы ярдәмендә уку эшчәнлегенең максатын билгеләү һәм формалаштыру;
-иллюстрация белән эш вакытында үзеңнең фикереңне, күзаллавыңны әйтергә өйрәнү;
-укытучы тәкъдим иткән план буенча эшләргә өйрәнү;
-дәреслек белән эшләү күнекмәләре булдыру;
-шигырьне сәнгатьле уку һәм хикәяне эзлекле сөйли алуга ирешү;
-үз фикереңне телдән һәм язмача белдерергә өйрәнү;
-уку бурычларын аңлау, аны чишү юлларын эзләү;
-"Татар теле" дәреслеге эчтәлеге буенча материаль һәм информацион мөхиттә эшли алу.
-Мөстәкыйль рәвештә дәреснең темасын һәм максатын билгеләү.
-Эшчәнлек өчен эш урыны әзерләү.
-Эшне планлаштырырга өйрәнү.
-Эшнең дөреслеген тикшерү.
-Эш сыйфатына бәя бирә белү.
-Эш барышында гади генә эш приборлары белән эш итә белү (линейка, бетергеч, карандаш, сүзлек дәфтәре).
-Укытучы белән бергәләп билге кую критерияләрен чыгару.
-Дәреслек белән эш итә белү.
-Текстны (хикәя, шигырь, әкиятне) сәнгатьле итеп уку.
-Текстта очраган таныш сүзләргә таянып, яңа сүзләрнең мәгънәсен төшенү.
-Текстны сәнгатьле итеп укыгач, сорауларга җавап бирү.
-Укытучының авыр булмаган сорауларына җавап бирә, тиешле мәгълүматны дәреслектән таба белү.
-Предметларны чагыштыра, охшаш һәм аермалы якларын билгели белү.
-Укылган яки тыңланган текстның эчтәлеген сөйли белү.
-Төрле сүзлекләрдән куллана белү.
- Гомуми уку күнекмәләрен һәм үз эшчәнлегеңне оештыра алу сәләтен формалаштыру;
-Дәрестә һәм төрле ситуацияләрдә диалогта катнаша белү.

-Укытучының, классташларының сорауларына җавап бирү.
-Сөйләм этикеты нормаларын үтәү: исәнләшә, саубуллаша, рәхмәт белдерә белү.
-Башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү.
-Парларда эшли белү.
**Предметлы нәтиҗәләр:**

-Телнең милли аңның нигезе булуы турында беренчел белемнәр формалаштыру;
-Татар теленең нормалары турында башлангыч белем күнекмәләре алу;
-Сүзләрне дөрес, аңлап алу;
-Телнең төзелеше, системасы турында белемнәр булдыру, телнең төп бершмлекләрен, аларның билгеләрен, аермалы якларын өйрәнү;
-Телнең төп берәмлекләрен, грамматик категорияләрен танырга һәм анализларга өйрәнү, тел берәмлекләрен дөрес итеп куллана белү.

**Фәнне үзләштерүнең планлаштырылган нәтиҗәләре 4**

**сыйныф укучылары белергә тиеш:**
- сүзләрне, җөмләләрне, 70-80 сүзле текстны, хәрефен бозмыйча, төшереп калдырмыйча, хәреф өстәмичә, урыннарын алмаштырмыйча, каллиграфик дөрес яза;

- җөмләдәге сүзләр бәйләнешен билгеләү һәм җөмләнең баш кисәкләрен һәм иярчен кисәкләрен таба;

-сүз һәм аның лексик мәгънәсен ачыклый

-хикәяләү характерындагы зур булмаган текстлар төзи;

-сүзнең мәгънәсен текст буенча яки аңлатмалы сүзлек ярдәмендә ачып бирә;

-бер һәм күп мәгънәле, туры һәм күчерелмә мәгънәле сүзләрне таба;

-синоним һәм антонимнарны таба;

-сүз төзелешен тикшерә;

-сүз төркемнәрен (исем, фигыль, сыйфат, зат алмашлыгы, рәвеш кисәкчә) билгели, аларга морфологик анализ ясый;

-сыйфатның дәрәҗәләрен аеру;

-җөмлә, сүзтезмә һәм сүзләрне аеру;

-әйтү максаты буенча җөмләләрне классификацияләү.

**4 сыйныф укучылары ия булырга тиешле күнекмәләр:**
-җөмлә ахырында нокта, сорау һәм өндәү билгеләрен дөрес кую;
-уку, көндәлек аралашу шартларында тел әдәбе нормаларын үзләштерә;
- текстны анализлау. Тексттан тиңдәш кисәкле җөмләләрне табу, билгеләү.
-Хатлар һәм котлау открыткалары хикәяләү. Текстны бәяләү, мәгънәви хаталарны ачыклау.
-хикәяләү характерындагы сочинение язу.

**Эш программасының төп эчтәлеге Сүз**
**. Телнең сүзлек байлыгы .Сүзнең лексик мәгънәсе.**

Сүз һәм аның мәгънәсе, бер генә мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләр, тотрыклы сүзтезмәләр, алынма сүзләр, синоним,антоним, омонимнар.Сүзне туры һәм күчерелмә мәгънәдә куллану. Искергән һәм яңа сүзләр. Бу белемнәрне гамәли сынап карау.

Татарча-русча, русча- татарча сүзлекләр, орфографик сүзлек, аңлатмалы сүзлек, фразеологик әйтелмәләр сүзлеге
.

**Сүз төзелеше**

4 нче сыйныфта “Сүз төзелеше” темасы тагында тирәнәйтелә: ясалма, кушма,парлы, тезмә сүзләрнең, ясалышы һәм дөрес язылышы,рус теленнән татар теленә кергән алынма кушма сүзләрнең үзенчәлекләре; сүз төзелешенә анализ ясау ,кушма сүзләрдә ь һәм ъ хәрефләренең язылыш кагыйдәләре, сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә сүз ясагыч кушымчаларның ялгану тәртибе. Сүз төзелешенә анализ.

**Сүз төркемнәре. Исем**

Мәгънәсе, сораулары, формалары, ясалышы, җөмләдәге урыны турында кабатлау. Исемнәрнең хәбәр булып килүләренә күзәтүләр. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр. Берлек һәм күплек сандагы исемнәр. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнеше. Калын һәм нечкә төрләнеш. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә кушымча ялгау. Килеш кушымчаларының дөрес язылышы.

Баш килеш. Бу формада исемнәрнең җөмләдә ия, хәбәр, иярчен кисәк була алулары. Төшем килешенең мәгънәсе, җөмләдәге функциясе. Күплек сандагы исемнәрнең килешләр белән төрләнеше. Төрле килешләрдә исемнәрнең бәйлекләр белән кулланылуы.

**Фигыль**

Фигыль - катлаулы сүз төркеме. 4 нче сыйныфта 1-3 нче сыйныфта үткән материал искә төшерелә һәм хикәя фигыльнең билгеле үткән заман, нәтиҗәле үткән заман формалары; киләчәк заман формалары: билгесез киләчәк заман, билгеле киләчәк заман турында яңа мәгълүмат өстәлә. Фигыльнең барлык һәм юклык формалары.

Боерык фигыль. Боерык фигыльнең мәгнәсе , зат-сан белән төрләнеше. Боерык фигыльне куллану, дөрес язу.

Фигыльнең җөмләдә хәбәр булып килүе, антоним Һәм синоним фигыльләр турында мәгълүмат бирү.

**Сыйфат**

Сыйфат дәрәҗәләре.Дәрәҗә формаларының ясалышы, дөрес язылышы һәм кулланылышы. Сыйфатның җөмләдәге роле (иярчен кисәкләр һәм хәбәр булып килүе).Сыйфатларның туры һәм күчерелмә мәгнәдә кулланылуы.Антоним сыйфатлар, синоним сыйфатлар.

**Алмашлык**

Алмашлык – мөстәкыйль сүз төркеме. Ул сөйләмдә башка сүз төркемнәрен (исем, сыйфат, сан һәм рәвешне) алыштырып килә. Алмашлык предметны яки билгене генә белдерми , ул бары тик үзе алыштырып килә торган сүз төркеменең грамматик билгеләренә ия була. Алмашлыкларның җөмләдәге роле. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, дөрес язылышы кабатлана һәм сорау алмашлыклары турында яңа мәгълүмат бирелә. Килеш сораулары сорау алмашлыкларына керәләр. . Алмашлыкларның сөйләмдә кулланылышы.

**Сан**

Сан предметның исәбен, микъдарын белдерә торган сүз төркеме. Сан исем белән кулланылганда төрләнми. Җөмләдәге роле. Кайбер сан төркемчәләре :микъдар саннары, тәртип саннары.

**Рәвеш**

Рәвеш - мөстәкыйль сүз төркеме, лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә.Рәвешләрнең җөмләдәге роле.

Морфологик яктан - төрләнми. Ул ничек? кайчан? кая? кайда? никадәр? күпме ? кебек сорауларга җавап бирәләр. Эш яки хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә торган сүз төркеме.

Сөйләмдә актив кулланыла торган рәвешләр, аларның дөрес язылышы.

**Кисәкчәләр**

Кисәкчәләр турында беренче мәгълүмат 3 нче сыйныфта бирелә. Кисәкчәләр (*да, дә, та, тә, гына, генә, кына, кенә, ук, үк, ич, бит*). Аларның дөрес язылышы.

Кисәкчәләр сүз яки җөмләгә төрле төсмер өстәү өчен кулланылуы ачыклана.Кисәкчәләр аерым торганда мәгънә белдерми. Бик күп кисәкчә күп мәгънәле була,һәм аларның мәгънә төсмерләре нинди сүзгә иярүләренә, кайсы урында килүләренә, җөмлә төзелешенә, аның интонациясенә карап үзгәрә.

**Бәйлекләр**

1-3 нче сыйныфларда өйрәнгәннәрне кабатлау. Бәйлек- ярдәмче сүз, шуңа күрә, төшенчәдә төп урынны бәйлекнең функциясе, үтәгән хезмәте алып тора: бәйлекләр сүзләрне бәйлиләр.Төрле килешләрдә исемнәрнең һәм зат алмашлыкларының бәйлекләр белән килүенә күзәтүләр. Бәйлек төшенчәсе грамматик категория итеп аңлатыла.

**Сүзтезмә**

4 нче сыйныфта сүзтезмәләргә шактый эзлекле мәгълүмат бирү күздә тотыла : сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлату, сүзтезмәләрнең барлыкка килү юлларын ныгыту, сүзтезмәдәге иярүче һәм ияртүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү.

**Җөмлә**

Җөмләнең баш кисәкләре. Баш һәм иярчен кисәкләрнең аермасы. Җөмләдә сүзләр бәйләнеше. Ия белән хәбәр билгеләмәсе . Җыйнак һәм җәенке җөмләләр .Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч. Аергычка билгеләмә бирү Һәм аның сыйфат белән белдерелүе .

**Җөмләнең тиңдәш кисәкләре**

Җөмләнең тиңдәш кисәкләрен һәм тиңдәш кисәкләрнең үзара санау интонациясен, теркәгечләр ярдәмендә бәйләнешен төшендерү, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләренең куелышын аңлату. Тиңдәш ияле һәм тиңдәш хәбәрле җөмләләр.Тиңдәш кисәкләр арасында ***һәм, я, да-дә, та-тә, ә, ләкин*** теркәгечләре, тиңдәш кисәкләр янында тыныш билгеләре.

Эндәш сүзләртурында төшенчә бирү. Эндәш сүзләр һәм алар янында тыныш билгеләрен куярга өйрәтү.

Гади һәм кушма җөмләләр турында төшенчә бирү. Составында 2-3гади җөмлә булган кушма җөмләләр**.** Тезмә кушма җөмләләрдә ***һәм, ә, ләкин, әмма*** теркәгечләре, алар янында тыныш билгеләре.

**Бәйләнешле сөйләм**

Сөйләм,аның тормыштагы роле. Билгеле бер темага караган төрле (сурәтләү, хикәяләү характерындагы) сөйләм текстлары кулланып, телдән монологик сөйләмне гамәли яктан үзләштерү.

Текст. Текст билгеләре. Тексттагы җөмләләрнең мәгънәви бердәмлеге. Текстка исем бирү.

Тексттагы җөмләләрнең эзлеклелеге. Текст кисәкләренең (өлешләренең) эзлеклелеге, кызыл юл турында төшенчә.

Текстка исем бирү, җөмлә һәм текст кисәкләрен билгеләү, җөмлә һәм текст кисәкләре эзлеклелеген төзәтү.

Текстның планын төзү. Бирелгән план буенча үз текстыңны төзү. Сурәтләү һәм

хикәяләү характерындагы текстлар, аларның үзенчәлекләре.

Котлау тексты һәм хат язу. Язма сөйләмнең төгәллеген, дөреслеген һәм сәнгатьлелеген саклап, үз текстыңны төзү һәм бирелгән текстларны тикшереп төзәтү, текстта синонимнар, антонимнар куллану.

Изложение һәм сочинениенең төп төрләре белән танышу (билгеләмәләрен ятламыйча): бирелгән текстны тулысынча файдаланып яки аерым урыннарын (сүзләрен) сайлап алып языла торган изложение, сочинение элементлары булган изложение, хикәяләү-сурәтләү рәвешендәге сочинение һ.б.

**Тематик планлаштыру**

| **4 нче сыйныф** | | |
|---|---|---|
| **1-3 нче сыйныфларда** | **5** | Фонетика,морфология һәм синтаксистан үткәннәрне кабатлау һәм тирәнәйтүне күздә тоту. Фонетикадан аваз һәм хәреф, алар арасындагы |

| | | |
|---|---|---|
| **үткәннәрне кабатлау** | | аерма, тартык һәм сузык авазлар, аерым авазларның дөрес әйтелешен һәм язылышын өйрәнү. Морфология буенча сүз төзелеше һәм арым сүз төркемнәре искә төшерү. Синтаксистан җөмлә һәм аның төрләре искә төшерү. |
| **Сүз. Телнең сүзлек байлыгы. Сүзнең лексик мәгънәсе.** | **6** | Сүз һәм аның мәгънәсен, бер генә мәгънәле һәм күп мәгънәле сүзләрне, алынма сүзләрне, синоним,антоним, омонимнарны искә төшерү. Бу белемнәрне гамәли сынап карарга өйрәнү. Төрле сүзлекләр белән эшләү күнекмәләрен ныгыту. |
| **Сүз төзелеше** | **9** | Ясалма, кушма,парлы, тезмә сүзләрнең ясалышы һәм язылышы, рус теленнән татар теленә кергән алынма кушма сүзләрнең үзенчәлекләре белән танышу. Сүз төзелешенә анализ ясарга өйрәнү. |
| **Сүз төркемнәре. Исем** | **12** | Исемнең мәгънәсе, сораулары, формалары, ясалышы, җөмләдәге урыны турында кабатлау.<br><br>Исемнәрнең хәбәр булып килүләрен күзәтүләр.<br><br>Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр, берлек һәм күплек сандагы исемнәр турында белемнәрен тирәнәйтү. Исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнешен тирәнтен өйрәнү.<br><br>Калын һәм нечкә төрләнеш белән танышу. Сингармонизм законына буйсынмаган сүзләргә кушымча ялгарга өйрәнү.<br><br>Килеш кушымчаларының дөрес язылышы белән танышу.<br><br>Баш килеш формасында исемнәрнең җөмләдә ия, хәбәр, иярчен кисәк була |

| | | |
|---|---|---|
| | | алуларына төшенү. Төшем килешенең мәгънәсе, җөмләдәге функциясе белән танышу. |
| **Фигыль** | **16** | Хикәя фигыльнең билгеле үткән заман, нәтиҗәле үткән заман формалары, киләчәк заман формалары: билгесез киләчәк заман, билгеле киләчәк заман турында яңа мәгълүмат алу.<br><br>Боерык фигыльнең мәгнәсе , зат-сан белән төрләнеше, боерык фигыльне куллану, дөрес язу турында белем алу.<br><br>Фигыльнең җөмләдә хәбәр булып килүе, антоним һәм синоним фигыльләр турында мәгълүмат алу. Фигыльгә морфологик анализ ясау. |
| **Сыйфат** | **7** | Сыйфат, аның мәгънәсе һәм сөйләмдә куллану. Сыйфатның сорауларын ныгыту. Сыйфатның төс, тәм, форма, күләм, характер һ.б. билгеләрне белдерүе белән танышу. Сыйфат дәрәҗәләре белән танышу. Кайбер сыйфатларны гына дәрәҗәгә куеп була.<br><br>Җөмләдә сыйфат исемне ачыклап килә һәм күбесенчә аергыч була. Сыйфатның исемгә бәйләнеп килүе. Сыйфатның җөмләдәге функциясе( аергыч, хәбәр), синоним һәм антоним сыйфатларны өйрәнү. Сыйфатка морфологик анализ ясау. |
| **Алмашлык** | **6** | Алмашлык турында гомуми төшенчә бирү.Алмашлыкларның җөмләдәге ролен өйрәнү. Зат алмашлыклары, аларның мәгънәсе һәм сөйләмдә кулланылышы. I, II, III зат алмашлыклары, аларның берлек һәм күплек сан формалары, килеш белән төрләнешен өйрәнү. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнеше, дөрес язылышын кабатлау һәм сорау алмашлыклары турында яңа мәгълүмат алу. Килеш сорауларының сорау |

| | | |
|---|---|---|
| | | алмашлыкларына керүен белү. Сорау алмашлыкларына тагын ***нинди, кайсы, ничек, ник, нигә, ничәнче*** кебек сүзләр керүе белән танышу. |
| **Сан** | **7** | Предметның исәбен, микъдарын белдерә торган сүз төркеме белән танышу.<br><br>Санның исем белән кулланылганда төрләнмә вен төшенү.<br><br>Җөмләдә аергыч, хәбәр һәм исемнән башка кулланылганда, җөмләнең бүтән кисәкләре дә була алуын аңлау.<br><br>Санның билгеләмәсе(мәгънәсе, сораулары) белән танышу.<br><br>Санның исемне ачыклап килүе, сан белән ачыкланып килгән исемнең саналмыш булуы, кайбер сан төркемчәләре(микъдар саннары, тәртип саннары) турында беренче мәгълүмат алу. |
| **Рәвеш** | **6** | Рәвешнең ничек?, кайчан? Кая? Кайда? Никадәр? Күпме? Кебек сорауларга җавап булып килүе, эш яки хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерә торган сүз төркеме булуын аңлау.<br><br>Мөстәкыйль сүз төркеме, лексик-грамматик яктан эш-хәлнең билгесен, ничек үтәлүен белдерүен, морфологик яктан – төрләнмәвен,<br><br>кайбер рәвешләрнең артыклык яисә чагыштыру дәрәҗәсендә килә алуларын аңлау.<br><br>Синтаксик яктан- җөмләдә фигыльне, сыйфатны һәм рәвешне дә ачыклап килүен, төп синтаксик функциясе- хәл икәнлегенә төшенү. |

| | | |
|---|---|---|
| **Кисәкчәләр.Бәйлекләр.** | **6** | Кисәкчәләрнең сөйләмдәге роле-мәгънә, хис төсмерләрен, раслау, инкяр итүне белдерүе белән танышу. Аларны сөйләмдә дөрес куллану.<br><br>Бик күп кисәкчәләрне күп мәгънәле була алуын һәм аларның мәгънә төсмерләре нинди сүзгә иярүләренә, кайсы урында килүләренә, җөмлә төзелешенә, аның интонациясенә карап үзгәрүен аңлау.<br><br>Бәйлекләр сүзләрне бәйләгәндә, килешкә якын мәгънә белдерүен, үзләреннән алда килгән сүзнең билгеле бер килештә торуын, соравы белән танышу. Шуңа карап бәйлекләрне өч төркемчәгә аерырыга (баш, юнәлеш һәм чыгыш килеше) өйрәнү. |
| **Синтаксис** | **12** | Сүзтезмә һәм тезмә сүзләр арасындагы аерманы аңлау, сүзтезмәләрнең барлыкка килү юлларын ачыклау, сүзтезмәдәге иярүче һәм ияртүче сүз турында белемнәрне тирәнәйтү.<br><br>Ия белән хәбәр таба белүне, сорауларын куюны ныгыту.<br><br>Җыйнак һәм җәенке җөмләләр турында белемнәрне ныгыту. Җыйнак җөмләне тиешле сүзләр өстәп, җәенкеләндерә белү, җәенке җөмлә эченнән баш кисәкләрне аерып алу кебек күнегүләр эшләнелә**.**<br><br>Аергыч турында мәгълүмат алу.<br><br>Җөмләдән иярчен кисәкләрне (аергычны) таба белү. |
| | | Тиңдәш ияле, тиңдәш хәбәрле, тиңдәш аергычлы җөмләләр турында мәгълүмат алу.<br><br>Тиңдәш кисәкләр арасында теркәгечләр булганда тыныш билгеләрен |

| | | |
|---|---|---|
| | | куярга өйрәнәләр.<br><br>Эндәш сүзләр турында мәгълүмат алалар.<br><br>Составында 2-3 гади җөмлә булган тезмә кушма җөмләләрне тиңдәш кисәкле гади җөмләләрдән аера һәм тикшерергә өйрәнү.<br><br>Теркәгечләрне һәм тыныш билгеләрен куюны өйрәнү. |
| **Текст. Бәйләнешле сөйләм.**<br><br>**Барлыгы** | **10**<br><br>**102** | Текстның темасын ,төп фикере, аның өлешләрен билгели белү осталыгын камилләштерәләр.<br><br>Текстларның төрләре (хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү). Текстларны бер-берсеннән аера һәм төзергә өйрәнәләр. Текстта сурәтләү чаралары. Текстларның эчтәлеген кыскартып һәм тулысынча сөйләү.<br><br>Котлау открыткасы, хат, СМС язарга өйрәнү.<br><br>Сөйләм этикасына караган күнегүләр. Аралашу ситуациясен – аралашу кем белән, кайда, нинди максат белән башкарылуын аңлау. Үз фикереңне әйтү һәм аны дәлилләү. Әңгәмә үткәрүнең төп күнекмәләрен үзләштерү (сүз башлау, әңгәмәгә кушылу, аны дәвам итү, игътибарны җәлеп итү һ.б.). Уку, көндәлек аралашу шартларында тел әдәбе нормаларын үзләштерү (сәламләү, хушлашу, гафу үтенү, рәхмәтле булу, сорау белән мөрәҗәгать итү).<br><br>Монологик сөйләм төзү күнекмәләрен камилләштерү. |

**Норма оценивания / Укучыларның укуын һәм белем күнекмәләрен бәяләү**

**Контроль күчереп язуны бәяләү**

Пөхтә, төгәл һәм орфографик хатасыз язылган эшкә “5”ле куела.

Пөхтә, төгәл язылган, әмма 1 – 3 төзәтү яки 1 – 2 орфографик хатасы булган эшкә “4”ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4 – 5 төзәтү яки 3 – 5 орфографик хатасы булган эшкә “3”ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 6 яки артыграк орфографик хатасы булган эшкә “2”ле куела.

**Диктантны бәяләү**

Пөхтә һәм төгәл язылган, 1 орфографик хатасы булган диктантка “5”ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылган, 2 – 3 орфографик хатасы булган диктантка “4”ле куела.
Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4 – 6 орфографик хатасы булган диктантка “3”ле куела.Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 7 яки артыграк орфографик хатасы булган диктантка “2” куела.

**Язма сөйләмне бәяләү**

2 – 4 нче сыйныфларда укучыларның язма сөйләм күнекмәләрен үстерү өчен, өйрәтү характерындагы изложениеләр һәм сочинениеләр яздырыла. Аларны бәяләгәндә, түбәндәгеләрне исәпкә алу сорала: эшнең эчтәлеге ягыннан тулы һәм эзлекле язылуы, грамоталы булуы. Башлангыч сыйныфларда изложение һәм сочинениеләр өчен бер билге куела.
Тәкъдим ителгән эзлекле язылган, 1 орфографик һәм 1 пунктуацион яки 1 грамматик хатасы булган эшкә “5”ле куела.
Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылган, ләкин эчтәлектә ялгыш җибәрелгән, 2 -3 орфографик һәм пунктуацион яки 2 – 3 грамматик хатасы булган эшкә “4”ле куела.
Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылмаган, 4 – 6 орфографик һәм пунктуацион яки 4 – 6 грамматикхаталы эшкә “3”ле куела.
Тәкъдим ителгән темага эзлекле язылмаган һәм эчтәлеге ачылмаган, 7 дән артык орфографик һәм пунктуацион яки 7 дән артык тупас грамматик хатасы булган эшкә “2”ле куела.

**Тест** биремнәре түбәндәгечә бәяләнә: “2”ле
– 5 тән кимрәк дөрес җавап. “3”ле – 5 дөрес
җавап.
“4”ле – 7 дөрес җавап. “5”ле
– 10 дөрес җавап.

## Методическое обеспечение / Методик кулланма

1 **Методик ярдәмлек:** И.Х.Мияссарова, К.Ф.Фәйзрахманова “Татар телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 4 нче сыйныфында эшләүче укытучылар өчен методик кулланма”, К.-“Мәгариф-Вакыт”, 2012

**Өстәмә ресурслар:**

Ахиярова М.Ж. “Татар теленнән иҗади сочинениеләр һәм изложениеләр язарга өйрәтү” 1 – 4. /Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2009/

Абдрәхимова Я.Х. Татар теленнән диктантлар. 1 – 4. /Казан, “Мәгариф” нәшрияты, 2009/

**Интернет –ресурслар:**

Татар телендә белем һәм мәгълүмат бирүче http://tatarschool.ru/, belem.ru, tazbash.narod.ru/ сайтлары

**Укытуның техник чаралары**

1. Укытучы ноутбугы.
2. Мультимедиа проекторы.
3. Доккамера.

.Татар теле, /Казан, “Мәгариф – Вакыт” нәшрияты, 2012/,И.Х.Мияссарова, К.Ф.Фәйзрахманова/. 2 кисәктә.

2. Татар теле дәреслекләренә мультимедиа кушымта . “Татар теле”, 4 класс, Мияссарова И.Х., К.Ф.Фәйзрахманова

**Диктант к промежуточной аттестации / Арадаш аттестация өчен диктант тексты**

**Ана һәм җир**

Туган җир! Нигә син шундый кадерле икән? Бездәге туган илне ярату тойгысы ата-бабаларыбыз йортыннан башлана. Әле син бер бала гына. Син үзеңнең дөньяда яшәвеңне дә белмисең. Ләкин синең карыныңа татлы сөт ага. Сөттән соң су сорыйсың син. Әниең синең авызыңа су сала. Сөт һәм су! Ана күкрәгеннән килгән сөт нинди пакь! Җир күкрәгеннән сөзелеп чыккан чишмә сулары да шундый ук. Шулай булгач, анага булган мәхәббәтен сөттән ак, җиргә булган мәхәббәтен чишмәдәй саф.

Менә нинди тойгылар уята үз җирең, үз көең! (80 сүз)

**Грамматик биремнәр.**

3 нче җөмләне сүз төркемнәре һәм җөмлә кисәге ягыннан тикшерегез; исемнәрнең килешләрен билгеләгез.

*ак, кадерле* сыйфатларын төрле дәрәҗәләргә куеп языгыз.

**Тикшерү эшенә таләпләр**:

-җөмлә башында һәм ялгызлык исемнәрдә баш хәреф;
-сүзләрдә о—ы, ө—есузыклары;
-ъ һәм ь хәрефләрекергәнсүзләр;
-кушмаһәмпарлысүзләр;
-сүз төркемнәрен аера белү;
-җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен табу;
-саңгырау һәм б, в, г, д тартыкларына беткән исемнәрдә килеш кушымчалары;
-борын авазларына беткән исемнәрдә килеш кушымчалары;

-иялек һәм төшем килешендәге исемнәрнең баш килеш формасында килү очрагы.

**Диктантны бәяләү**

Пөхтә һәм төгәл язылган, 1 орфографик хатасы булган диктантка “5”ле куела. Пөхтә һәм төгәл язылган, 2 – 3 орфографик хатасы булган диктантка “4”ле куела.

Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 4 – 6 орфографик хатасы булган диктантка “3”ле куела.Пөхтә һәм төгәл язылмаган, 7 яки артыграк орфографик хатасы булган диктантка “2” куела.

**Лист корректировки / Төзәтмәләр кертү бите**

| Название раздела темы / Бүлек теманың исеме | Причины корректировки / Төзәтмәләр кертү сәбәбе | Корректирующие мероприятия / Төзәтмә кертү чаралары | Дата проведения / Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|
| | | | план | факт |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |
| | | | | |

**График проведения контрольных работ / Контроль эш программасы**

| **№ п/п** | **Тема урока / Дәрес темасы** | **Дата проведения / Үткәрү вакыты** |
|---|---|---|

| | | план | факт. |
|---|---|---|---|
| 1 | Повторение изученного в 1-3 классах Входной контрольный диктант./ 3 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау . Кереш контроль диктант | | |
| 2 | Контрольный диктант по разделу “Слово”. /“Сүз ” темасы буенча контроль диктант. | | |
| 3 | Тест по теме “ Состав слова. Словообразование” / “Сүз төзелеше. Сүз ясалышы ”темалары буенча тест**.** | | |
| 4 | Диктант по теме “ Слово” ./ “Сүз ” темасы буенча диктант. | | |
| 5 | Творческая работа по теме “ Части речи”. Изложение./ “Сүз төркемнәре” темасына иҗади язма эш. Изложение. | | |
| 6 | Объяснительный диктант по разделу “Имя существительное”./ “Исем” темасы буенча аңлатмалы диктант. | | |
| 7 | Контрольное списывание по теме “ Глагол”. / “Фигыль” темасы буенча контроль күчереп язу. | | |
| 8 | Развитие речи “ В столовой”. / Б.с.ү.” Ашханәдә”. | | |
| 9 | Контрольный диктант за 1 ое полугодие./ 1 нче яртыеллыкка контроль диктант. | | |
| 10 | Сочинение “ Мой друг”. / “Минем дустым” темасына хикәя язу. | | |
| 11 | Контроьлное списывание. / Контроль күчереп язу. | | |
| 12 | Развитие речи “ Моя любимая книга”./ БСҮ “Яраткан китабым” | | |
| 13 | Контрольный диктант по теме “ Местоимение» / «Алмашлык» темасы буенча контроль диктант. | | |
| | Развитие речи “Книга – источник знаний”/ Хикәя “ Китап – белем чишмәсе” | | |
| 14 | Сочинение “Наступила весна”. / “Ямьле яз килә” темасына инша. | | |
| 15 | Контрольное списывание. /Контроль күчереп язу. | | |
| 16 | Контрольное изложение. / Контроль изложение | | |
| 17 | Диктант по разделу “Предложение”. / “Җөмлә”темасы буенча диктант. | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 18 | Промежуточная аттестация.Контрольный диктант / Арадаш аттестация.<br>Еллык контроль диктант. | | |